**«Виктория» исемендәге XII Халыкара балалар һәм яшүсмерләр иҗаты фестиваль-конкурсы**

19нчы апрель көнне лицеебызның «Заман» фольклор ансамбле «Виктория» исемендәге XII Халыкара балалар һәм яшүсмерләр иҗаты фестиваль-конкурсында катнаштылар. Яшь оешкан ансамбль булуына карамастан, җитәкчесе Абакаева Ләйсән Камилевна укучылар белән төрле чараларда актив катнашып йөриләр. Әлеге “Виктория” исемендәге фестиваль-конкурста да катнашып, бик күп конкурентлар арасыннан 3нче урын яулап кайттылар. Ансамбль кызлары югары дәрәҗәдә матур чыгыш ясадылар. Алар керәшен халык җыры “Җиләк җыйдым” дигән җыр әзерләгәннәр иде, тамашачы зур алкышлар белән бәяләде. Ансамбльга киләчәктә зур уңышлар телибез һәм яңадан яңа үрләр яуларга насыйп булсын!




2021